

Сугыш балаларынын язмышлары торле, әмма аларнын барысын да уртак фажига берләштерә: балачакнын матур доньясын кире кайтарылмаслык югалту. Ләмберә районында агымдагы ел башына Сугыш балалары статусына 1000гә якын кеше ия. Аларнын балачагы 1941 елнын 22 июнендә туктый. Ил очен авыр вакытта аларнын һәрберсе, ачлык һәм куркуга карамастан, vз батырлыгын башкара: укуларын дәвам итәләр, фронтка посылкалар жибәрәләр, басуларда эшлиләр. Якташларыбыз vз хезмәтләре белән Боек Жинvне ничек якынайтулары турында Ләмберәнен сугыш балалары һәм олкән буын активистлары белән очрашу багышлана. Бу чара РФ Пенсия фонды һәм социаль иминиятләштерv Ләмберә районы бvлекчәсе бинасында узган.

Әлеге кичә Боек Жинvнен 79 еллыгын бәйрәм итv алдыннан моһим вакыйга булган. Анда шулай ук Ләмберә районы башлыгы Юрий Иванович Голов, анын социаль эш буенча урынбасары Румия Хаким кызы Салимова, Саранскидан килгән кунаклар катнашты. Ләмберә Пенсия фонды һәм социаль иминият бvлеге вәкиле Ирина Рустам кызы Садыйкова офиснын актлар залында жыелганнарны чын кvнелдән сәламләде һәм барысын да май бәйрәмнәре белән котлады. Аннары ул узган очрашуда катнашучыларга узган елнын октябреннән олкән буын аралашу Үзәге эше турында жентекләп сойләгән. Шунысы куанычлы, узган жиде айда бу vзәктә биш локация буенча 120дән артык торле чара уздырылган. Бу тәжрибәле табибларнын лекцияләре, психологлар белән дәресләр һәм компьютер грамоталылыгын арттыру,



кызыклы кешеләр белән очрашулар, кулинария һәм кул эшләре буенча мастер-класслар һәм башкалар. Ә кvп кенә пен-сионерлар Пенсия фонды һәм социаль иминият бvлеге бинасы территориясен яшелләндерvдә зур теләк белән катнашалар. Еш кына кайбер кунаклар оныклары белән аралашу Үзәгенә киләләр һәм аларнын һәрберсе монда кvнелле шогыль таба. Ин моһиме, кешеләр vзләрен зур дус коллективнын бер олеше итеп хис итәләр.
Кvп кенә пенсионерларнын актив рәвештә vз оешмаларында катнашучыларга ярдәм итәргә теләvләре аерым игътибарга һәм мактауга лаек. Мәсәлән, маскировка челтәрләре vреп, армия очен коры душ ясыйлар, жылы йон оекбашлар һәм бияләйләр бәйлиләр, озак саклана торган азык-толек жыелмаларын жыялар. Аннары боларнын барысын районнын гуманитар ярдәм жыю пунктына тапшыралар. Шунысын да билгеләп vтәргә кирәк, кыска вакыт эчендә “комеш” яшьтәге Ләмберә волонтерлары 20дән артык маскировка челтәрен vреп бетергән. Нәтижәдә, алар vз адресына “Мордовия Республикасы Ватан сугышчылары гаиләләре комитеты”ннан Рәхмәт хаты алган.

